

Ренат Наиль улы Ләмберәнен «Нива» җәмгыятчелегендә ветеринария табибы булып эшли. Анын турында бик кvп мактаулы сvзләр әйтергә була. Бер очракны гына алыйк - ул алыштыргысыз хезмәткәр. Аны еллар буе ялга да җибәрә алмыйлар, чонки ана алмашка белгеч юк.
Язма героебыз Ләмберә авылында туган. Ул кечкенәдән ук безнен кече дусларыбыз - хайваннарны яратып vсә. Әти-әниләре ул чорда, ишегалдында авыл vлчәмнәре буенча, гадәти терлек - кәҗә, бозау, тавыклар асраганнар. Наиль улы Ренат балачакта ук малкайларны ашатырга, аларны чисталыкта тотарга, кышлыкка печән әзерләргә кvнеккән.

Авылы мәктәбен тәмамла-ганнан сон, ул ПТУ-14 укып, замана очен кирәкле крановщик һәм автослесарь һонәрләренә ия булган. Бу юнәлештә vзен тормышка ашырып, Саранск-та ул яхшы гына топләнер иде. Тик Ренатнын кvнеле башка һонәрдә. Бу юнәлештә кискен карар кылып, Н.П.Огарев исемендәге МГУнын авыл хуҗалыгы факультеты «Ветеринария»  бvлегенә укырга керә. Университета белгечлек дипломы алганнан сон, Ринат Наиль улы Ибраһимов авыл Айболитына әверелә; доресрәге, Ләмберәсенен «Нива» җәмгыятчелегендә ветеринар булып эшли башлый. Тик бу елларда хезмәт хакы тvбән була, ә өйләнгән гаилә башына гаиләне туендырырга кирәк бит! Шул максаттан ул Мәскәvгә тозелешкә юл ала. Әмма аны һәрвакыт ое vзенә тарта. Нәтиҗәдә ул, туган ягына кайтып, хезмәт биографиясен башлап җибәргән Ләмберәдәге «Нива» җәм-гыятчелегенә хезмәткә урнаша һәм ун елдан артык инде ветеринария олкәсе баш табибы булып эшли. Әйтеп китәргә кирәк, бvгенге хезмәт хакы - лаеклы һәм аны канәгатьләндерә, кайчагында кыенлыклар тудырса да. Сvз унаеннан искә тошерим, ООО «Нива»да могезле эре терлекнен баш саны 1100 тәшкил итә. Шул санны исәпкә алган очракта, һәрбер терлек турында кайчан кайгыртып олгерә сон ул дигән сорау туа. Бу сорауны ана мәкалә авторы Михаил Танин бирә: “Сезнен хезмәт коне ничек башлана?”
Әнгәмәдәше ана: “Иртәнге сәгать 7дә мин эштә, сонрак ярамый, чонки бу вакытта бездә планерка бара. Аннан сон малларны карап чыгам, аларны ойрәнәм, авыруларын

ачыклыйм. Арада булган ике-оч авырган малкайга ярдәм итәбез, сыерларга аппетит кvтәрv очен катнашмалар салабыз, дарулар бирәбез, кирәк чакта, операциялибез. Дару артыннан Саранскка барырга туры килә, ТЭЦ-2да яхшы ветаптека бар. Анда персонал - молодцы, кирәкле дарулары һәрвакыт бар; әгәр нәрсә дә булса кирәк икән - консультациялиләр.”
Малкайларнын vлеп китve дә бар бит, бу бик тә актуаль сорауга да жавап аласы килә. Ренат Наиль улы барыннан да ешрак азыкка кадак яки тимер чыбык эләгve куркыныч, ди. Малнын ашказанына кергән очлы әйберләр органны жәрәхәтли, алай гына да тvгел, алга таба йорәккә кадалуы, сыер кикерә алмый азаплануы vлемгә китерә, дип анлатты. Менә шундый очраклар да була икән.
Кон, ел әйләнәсе хезмәттә булган кешенен ялы кайчан була икән дип тә сорарсыз. Мона табиб болай ди: “Ойдә, гадәттә, кичке алтыдан сон булам; бәйрәмнәрсез, ялларсыз эшлим. Ял – атнага бер кон. Тик теләсә кайсы вакытта чакыртырга момкиннәр, мәсәлән, сыер бозаулаганда ярдәм кирәксә. Бvген менә тон уртасында йокыдан уяттылар; фермага сыер эченә укол ясарга килгән идем. Ял турында сойләгәндә шундый очрак исемә тоште. Мине ничектер санаторийга жибәрделәр, әмма шул вакыт сыерлар кvпләп бозаулый башладылар һәм путёвкадан баш тартырга туры килде. Быел, ниһаять, бәхет елмайды: гаилəм белән Абхазиядә ял итә алдык. Мин беренче тапкыр ялда булдым. Берничә ел Абхазиядә яши торган апам, Римма Касыйм кызы янына тукталдык. Ана табиблар климатны vзгәртергә, биредә яшәргә кинәш иткән иделәр.
Абхазия - ботенләй башка донья. Климат та районыбызныкыннан яхшы. Биредә дә малкайлар турында кызыксындым. Мәсәлән, бу як сыерлары, атлары авыл урамнары буенча йори; аларны берәv дә кумый, куркытмый. Сыерлар болыннарда рәхәтләнеп ашап сот жыя. Трассага да ятарга момкиннәр: бу очракта машина аларны әйләнеп чыга. Кичен, саварга вакыты житкәч, vзләре ойгә кайта. Бердәнбер куркыныч - бvреләр; алар таудан тvбән тошә, икән. Дорес, анда сыерлардан сот аз бирә. Әгәр безнекеләрдән 20 литр сот саусак, абхазлылардан - 5 литр, әмма соте бик майлы, икән.
Ренат Ибрагимовнын шәхси торагы, хужалыгы  турында кызыксын-дык. Башта алар язма герое тормыш иптәшенен әти-әнисе фатирында яшәгәннәр. Ә кvптән тvгел, Мордовия авыл хужалыгы министрлыгы линиясе буенча, 1,5 миллион сум субсидия алган. Ренат Наильевич агымдагы елнын апрелендә зур йорт салып яши башлый. Бакчага кирәкле яшелчә һәм жиләк-жимеш тә утыртып уныш жыярга олгерә. Әлегә тавыклар гына алып кайткан, алар очен кечкенә генә сарай да корып олгергән.
Гаиләсе анын матур, чонки алар vзара дус, тату яшиләр. Тормыш иптәше профессиясе буенча чәчтараш-парикмахер. Улы юрист булырга карар кылган; 9 сыйныфтан сон Россия хокук Академиясенә профессия vзләштерергә кергән. Кызына әле 5 яшь кенә: укытучы булырга жыена, тик анын хайваннар белән кызыксынуы бар. Кайчагында, бигрәк шимбә конне, әтисе янына йогереп житә. Бозаулар бик ошый ана, ә менә зур сыерлардан әлегә курка. Тора бара кем буласы кvренер әле.
Менә тагы Ренатнын алыштыргысыз эш урынына әйләнеп кайтыйк. Бер сорау борчый, белгечкә биреп карыйк: “Ни очен егетләр, авыл хужалыгы факультетларында укысалар да, авылга эшкә кайтырга ашыкмыйлар икән?” Ул: “Безгә дә берничә тапкыр яшь белгечләр килде. Кайтып та киттеләр. Мин дә алардан: ни очен китәсез дип сорый идем. Ошамый, кvнел ятмый, дип жавап бирделәр. Ә бу ин моһиме. Менә мин vз эшемне яратам!
Остазларым аеруча яраттылар vз профессияләрен; ветеринария табибы Николай

Семенович Прокин һәм хужалыкнын баш зоотехнигы Александр Вениаминович Наточеев. Алар беренче чорда мина бик нык булыштылар, профессиямне тагы да яратырга ярдәм иттеләр. Авырлыкларга карамастан, эш пычрак булса да, кайвакыт нормалаштырылмаган кон булуга карамастан, тулы коч-куәт таләп итә торган эш булса да, vз эшенә тугры булырга кирәк. Элек хезмәт хакы тvбән булу куркыткан иде, ә хәзер монын белән барысы да әйбәт. Хезмәт шартлары vзгәрде. Машина белән сыер саву кертелде. Сvз унаенда шуны әйтәсе килә: сыер савучылар белән проблема юк, бездә аларнын 12 - тулы штат. Остәвенә, яшьләр килә - омет уяна.”
Ренат Наиль улы, сез vз эшегезне бик яратасыз, ә сезне сыерлар яратамы, дигән сорау биредә урынлы дип саныйм. Һәм шул урында тырыш ветеринар болай дип жавап бирде: “Алар миннән курка. Мин аларга укол ясыйм бит. Шприц белән керсәм, кvзләрендә куркыныч барлыгын сизәм, тик кайвакыт, рәхмәтләрен дә тоям”.
Менә шундый табиблар авылны кvб-рәк яшәтсен иде.

**Наилә НАСЫРОВА әзерләде**